ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮРТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЮРТАУ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Карары

№22 2019 елның 19 апрель 16

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Юртаү авыл җирлегендә вафат булганнарны җирләү буенча хезмәтләргә гарантияләнгән исемлек нигезендә күрсәтелүче хезмәтләрнең бәясен раслау турында

2003 елның 06 октябендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"гы №131-ФЗ Федераль законы, 1996 елның 12 гыйнварындагы "Татарстан Республикасында кабер казу һәм җирләү эше турында"гы Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 18.05.2007 елдагы "Татарстан Республикасында кабер казу һәм җирләү эше турында"гы Федераль законын тормышка ашыру буенча чаралар турында"гы №196 карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 24 гыйнвар, 2019елдагы" 2019 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында"гы №32 карары нигезендә Минзәлә муниципаль районының Юртаү авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1. 2019 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Юртаү авыл җирлегендә вафат булганнарны җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә бирелә торган хезмәтләрнең бәясен 5946,47 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2.Әлеге карар 2019 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбетләренә кагыла.
3.Гамәлдәге карар рәсми төстә басылырга тиеш.
4.Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче И.Ю.Кадыров